КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 3 февраль г.Казань № 48

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 10 июль, 348 нче; 2007 ел, 20 апрель, 136 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2013 ел, 2 февраль, 69 нчы; 2013 ел, 24 июнь, 436 нчы; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2016 ел, 20 февраль, 103 нче; 2016 ел, 6 август, 536 нчы; 2017 ел, 15 июль, 497 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче; 2017 ел, 28 декабрь, 1070 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1126 нчы; 2018 ел, 12 май, 350 нче; 2018 ел, 18 май, 375 нче; 2018 ел, 24 июль, 592 нче; 2018 ел, 8 сентябрь, 762 нче; 2018 ел, 13 декабрь, 1127 нче; 2019 ел, 19 апрель, 311 нче; 2019 ел, 25 декабрь, 1192 нче; 2020 ел, 11 февраль, 94 нче; 2020 ел, 17 март, 196 нчы; 2020 ел, 17 март, 196 нчы; 2020 ел, 28 июль, 629 нчы; 2020 ел, 2 октябрь, 902 нче; 2020 ел, 06 ноябрь, 1000 нче, 2020 ел, 30 декабрь, 1259 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктта «банк учреждениеләрендә исәп-хисап һәм башка счетлар» сүзләрен «законнарда билгеләнгән тәртиптә ачыла торган счетлар» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.20 пунктта «Татарстан Республикасы һәм аннан белешмәләр бирү» сүзләрен «һәм Татарстан Республикасында торак пунктлар» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин